**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422724, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422724, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 ноябрь 2018 ел** **№154**

# 2018 елның 18 ноябрендә “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 18 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында"гы карары нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдумны 2018 елның 18 ноябрендә узган, ә референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.
2. "2019 елда авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:
- Алан-Бәксәр авылында чишмәне карап тоту;
- Алат авылында поселок эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау;
- Гәр авылында һәйкәлне карап тоту?”
3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http:/ vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина